КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 18 июнь г.Казань № 482

«Мәскәү - Владимир - Түбән Новгород - Казан - Уфа 761+500 км - 771+246 км, Татарстан Республикасы участогында М-7 «Идел» автомобиль юлын реконструкцияләү» федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектын урнаштыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервлау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 70[0]1 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлауга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2008 елның 22 июлендәге 561 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Мәскәү - Владимир - Түбән Новгород - Казан - Уфа 761 + 500 км – 771 + 246 км, Татарстан Республикасы участогында М-7 «Идел» автомобиль юлын реконструкцияләү» федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектын урнаштыру максатларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан резервлана торган схемада билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрендә 1 нче кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләре өч елга Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

җир кишәрлеген максатчан билгеләү һәм аны рөхсәт ителгән файдалану нигезендә торак, җитештерү, мәдәни-көнкүреш һәм башка биналар, корылмалар торгызу, сугару, киптерү, агроурманмелиоратив, мәдәни-техник һәм башка мелиоратив эшләрне рөхсәт ителгән файдалану, сулыкларда буалар (шул исәптән су агызу урыннарында су асты корылмалары төзелгәннәр) һәм башка су объектлары төзү буенча башкару өлешендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен аларны резервлауга бәйле рәвештә җир законнары нигезендә җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең, җир кишәрлекләрен арендалаучыларның хокуклары;

кызыксынган затларны резервланучы җир кишәрлекләре схемасы һәм резервланучы җирләр чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең кадастр номерлары исемлекләре белән таныштыру Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы бинасында түбәндәге адрес буенча гамәлгә ашырыла: Казан шәһәре, Вишневский урамы, 26 йорт (эш режимы: дүшәмбе - пәнҗешәмбе: 9.00 - 18.00, җомга: 9.00 - 16.45, төшке аш: 11.45 - 12.30).

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә:

күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен документлар Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырырга;

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга;

әлеге карарны муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Югары ослан муниципаль районына җибәрергә.

4. Әлеге карар резервланучы җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш һәм басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                        А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 18 июнь, 482 нче
карарына 1 нче кушымта

«Мәскәү - Владимир - Түбән Новгород - Казан - Уфа 761+500 км - 771+246 км, Татарстан Республикасы участогында М-7 «Идел» автомобиль юлын реконструкцияләү» федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектын урнаштыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервлана торган җир кишәрлекләре исемлеге

| Т/с | Җир кишәрлегенең кадастр саны | Бердәм җирдән файдаланунын кадастр саны |
|---|---|---|
| 1 | 16:15:121401:1317 | |
| 2 | 16:15:121401:1326 | |
| 3 | 16:15:121401:1318 | |
| 4 | 16:15:121401:82 | 16:15:000000:236 |
| 5 | 16:15:121401:1302 | |
| 6 | 16:15:121401:1340 | |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 18 июнь, 482 нче
карарына 2 нче кушымта

«Мәскәү - Владимир - Түбән Новгород - Казан - Уфа 761+500 км - 771+246 км, Татарстан Республикасы участогында М-7 «Идел» автомобиль юлын реконструкцияләү» федераль әһәмияттәге капиталь төзелеш объектын урнаштыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен резервлана торган җир кишәрлекләре схемасы

Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы, Введенск-Бистәсе авыл җирлеге резервлана торган җирләрен урнаштыру схемасы




Масштаб 1 : 25000

Татарстан Республикасының Югары Ослан муниципаль районы, Введенск-Бистәсе авыл җирлеге резервлана торган җирләре схемасы




Масштаб 1 : 6000

Шартлы билгеләр:

16:15:121401:1595 - җир кишәрлегенең кадастр саны

- дәүләт ихтыяҗлары өчен резервлана торган җир кишәрлекләре
- башка җир кишәрлекләре
- пикетаж билгеләнеп, автомобиль юлының проект күчәре